**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

24.04.2024

Казан шәһәре

№ 217

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябреннән «Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 307 нче номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**Б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябреннән «Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 307 нче номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 11 ноябреннән 356 нчы номерлы, 2020 елның 17 июленнән 216 нчы номерлы, 2020 елның 9 октябреннән 287 нче номерлы, 2021 елның 22 июненнән 234 нче номерлы, 2021 елның 8 октябреннән 384 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бирергә:

2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февраленнән «Башкарма хакимиятнең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында  һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 175 нче номерлы карары белән расланган башкарма хакимиятнең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә;

Әлеге боерык белән расланган Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр в.б. Х.Х.Шәйхетдинов

2019 елның 7 октябреннән
Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
307 номерлы боерыгы белән
расланган (Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының 2024 елның
24 апреленнән 217 нче номерлы
боерыгы редакциясендә)

**Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү (шундый федераль органнарга караганлыгы дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга караган федераль органнар хезмәткәрләренә бирелгән очраклардан тыш) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр тора: тиешле спорт төре буенча төбәк спорт федерацияләре, 2007 елның 4 декабреннән «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль законның 25 маддәсендәге 6 өлеше буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмалары (алга таба – ФСО) яки федераль орган бүлекчәләре (хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләре өчен), кандидатның яшәү урыны буенча (Татарстан Республикасы территориясендә) яки төбәк спорт федерациясе эшчәнлегенең территориаль өлкәсе урыны буенча яки федераль орган бүлекчәсе урнашкан урын буенча (Татарстан Республикасы территориясендә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч тәртибенә нигезләнгән вәкаләтләр нигезендә эш итүче гариза бирүченең вәкиле (алга таба – гариза бирүче вәкиле) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профильләү (гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү вариантына ярашлы рәвештә, гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелгән анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән билгеләренә туры китереп дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы.

Спорт хөкемдарларының квалификация категорияләрен бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы.

2.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җававплы орган – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык).

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә, үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) (гариза кабул итү һәм консультация бирү өлешендә) катнаша.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, КФҮ аша мөрәҗәгать иткән очракта КФҮнең, Регламентның 2.7 пункты таләпләренә туры китереп, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) боерык белән рәсмиләштерелгән спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында карар (1 нче кушымта).

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту  турында карар (4 нче кушымта).

2.3.2. Спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында карар реквизитлары:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар номеры һәм датасы;
- карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;
- гариза номеры һәм датасы;
- гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) ;
– карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат)вазифасы;
- вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) ;
- электрон имза турында мәгълүмат.

2.3.3 Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

- дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар номеры һәм датасы;
- карар кабул итүгә вәкаләтле органның атамасы;
- гариза номеры һәм датасы;
- гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта);
– дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләре;
- вәкаләтле затның (алга таба - вәкаләтле зат)вазифасы;
- вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) ;
- электрон имза турында мәгълүмат.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып реестр язмасы тормый.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе нинди дә булса мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы:

шәхсән кәгазьдә;

- КФҮ аша;

– электрон рәвештә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – ДХБП) федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (https://www.gosuslugi.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) төбәк порталы (алга таба Республика порталы) (www.uslugi.tatar.ru) аша;

- почта аша.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты.

2.4.1. Дәүләт хезмәте, гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап почта аша яки шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Министрлыкта гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 19 көн эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, гариза бирүченең ДХБП, Республика порталында шәхси кабинеты (алга таба – шәхси кабинет) аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте ДХБП, Республика порталында шәхси кабинетында чагылыш таба торган эшләр номенклатурасы нигезендә, гаризага номер бирелгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 19 көн вакыт эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте, гариза бирүче КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, Министрлыкта гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап, шулай ук КФҮ Регламентында каралган срокны исәпкә алый, эш көннәрендә исәпләнә торган 19 көн эчендә күрсәтелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

ДХБП, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында (https://minsport.tatarstan.ru/) түбәндәгеләр урнаштырылган:

- дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

- дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүмат;

- Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны бирә:

а) тиешле спорт төре буенча төбәк спорт федерациясе, ФСО, федераль орган бүлекчәсе (хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләре өчен) җитәкчесе яки вәкаләтле вазыйфаи затның мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән расланган тәкъдим (алга таба – гариза) (2 нче кушымта);

б) төбәк спорт федерациясе, ФСО, федераль орган бүлекчәсе җитәкчесе яки вәкаләтле вазыйфаи затның мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән расланган исәпкә алу карточкасының күчермәсе (3 нче кушымта);

в) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук кандидатның яшәү урыны турында мәгълүматлар булган битләрнең күчермәләре, ә ул булмаганда – оРоссия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданының шәхесен раслаучы фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган атамасы, документның гамәлдә булуы чыгу датасы турында мәгълүматлар булган Россия Федерациясе гражданины паспорты битләренең күчермәләре Россия Федерациясе гражданнары өчен;

Шәхесне раслаучы документтан алынган мәгълүматлар, электрон формада тапшырганда, тиешле кырларга интерактив портал формада кертелә һәм шәхси мәгълүматлар өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шартларында ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, сорау җибәрү юлы белән тикшерелә;

г) чит ил гражданы паспортының яисә 2001 елның 7 августыннан «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юуга) һәм терроризмны финанслауга каршы тору турында» 115-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 115-ФЗ номерлы федераль закон) белән билгеләнгән яисә Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә чит ил гражданы шәхесен раслаучы документ буларак танылган башка документ күчермәсе – чит ил гражданнары өчен;

д) чит ил дәүләте тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документ буларак таныла торган документ күчермәсе яки 115-ФЗ номерлы федераль законда каралган яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документ буларак таныла торган башка документ күчермәсе – гражданлыгы булмаган затлар өчен;

е) хәрби билет күчермәсе – чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтәүче хәрбиләр өчен (Россия Федерациясе гражданы паспорты булмаган очракта);

ж) «Россиянең халыкара класслы спорт мастеры», «Россия гроссмейстеры» яки «Россия спорт мастеры» таныклыкларының күчермәсе – тиешле спорт төре буенча «Россиянең халыкара класслы спорт мастеры», «Россия гроссмейстеры» яки «Россия спорт мастеры» спорт исеменә ия булган кандидатлар өчен.

2.6.1.1. Регламентның 2.6.1 пунктының г һәм д пунктчаларында каралган чит ил дәүләте тарафыннан бирелгән документларны тапшырганда – электрон формада нотариусның электрон имзасы белән имзаланган расланган аларның тәрҗемәсе, кәгазьдә тәрҗемәнең нотариаль расланган күчермәсе бирелә.

2.6.1.2. Регламентның 2.6.1 пунктында каралган гариза һәм документлар спорт хөкемдарларының тиешле квалификация категорияләрен бирүгә квалификация таләпләре (алга таба – квалификация таләпләре) үтәлгән көннән алып 4 ай эчендә бирелә.

2.6.2. Документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга мөмкин:

1) кәгазьдә һәм 2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 63 – ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре буенча имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә КФҮ аша.

Гариза биргәндә гариза бирүчегә КФҮтән теркәлү номеры һәм электрон гариза бирү датасы куелган гариза җибәрелгәнен раслаучы расписка бирелә;

2) ДХБП, Республика порталы аша электрон формада.

Гаризаны ДХБП, Республика порталы аша җибәргәндә гариза бирүче гариза биргән көнне шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү

номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән гариза җибәрелгәнен раслаучы хәбәрнамә ала.

Гариза бирүчеләр гариза һәм кирәкле документларны ДХБП, Республика порталы аша юллаганда, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ИАБСда теркәлү (аутентификация үтү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын стандарттан да түбән булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

Гаризаны ДХБП, Республика порталы аша тапшырганда гариза бирүче, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә шундый документларны ясау һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларның электрон образларын яисә электрон формадагы документларны тәкъдим итә;

3) шәхсән кәгазьдә

4) почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән.

Почта элемтәсе аша җибәргәндә документлар күчермәләре билгеләнгән тәртиптә раслана.

2.6.3. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

1) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы мәгълүматлар - Федераль нотариаль контора;

2) яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәү исәбе турында мәгълүматлар –Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы;

3) Россия Федерациясе гражданы паспортының чынлыгы турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы .

2.6.4. Гариза бирүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алына торган документларны үзе мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматлар булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

2.7.1. Карауга документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

1) хезмәт күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтләренә кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яки оешмага бирелгән;

2) ДХБП һәм Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (чын булмаган, дөрес булмаган яки тулы булмаган тутыру);

3) Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган тапшырылган документларның үз көчләрен югалтуы

5) тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм текстта төзәтүләр булу;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган кимчелекләр булуы;

7) документларның тәкъдим ителгән электрон образлары документ текстын тулы күләмдә укырга һәм (яки) документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми – ДХБП һәм Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

8) «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү – ДХБП һәм Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

9) Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә кермәгән затның гариза белән мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабат мөрәҗәгать итүенә комачауламый.

2.7.3. Дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 5 нчы кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 2.3.5 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе белән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне бирелә (җибәрелә).

2.7.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар ДХБПда, Республика порталы һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге:

1) квалификация категориясе бирү өчен документларда дөрес булмаган мәгълүматлар ачыклану;

2) Квалификация таләпләренең үтәлмәве.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза ДХБПда, Республика порталы һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү дән баш тарту тыела.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентның 4 нче кушымтасында билгеләнгән формага

ярашлы рәвештә рәсмиләштерелә, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзалана һәм гариза бирүчегә бирелә (җибәрелә).

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Гариза бирүченең кабул итү (хезмәт күрсәтүне) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты.

2.11.1. КФҮ кә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, вазифа инструкциясе нигезендә гариза кабул итү һәм теркәү буенча бурычларны гамәлгә ашыра торган КФҮ хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) гаризаны кабул иткән көнне терки.

Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гариза һәм аңа теркәлеп бирелгән документларны Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.

Министрлыкта КФҮтән кергән гариза һәм аңа теркәлеп бирелгән документлар кабул ителгән көнне теркәлә.

2.11.2. Гаризаны ДХБП, Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне ДХБП, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы белдерү кәгазе ала, анда теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән була.

2.11.3. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәү гариза биргән көнне гамәлгә ашырыла.

2.11.4. Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган бинада башкарыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелгән урынга (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү) каршылыксыз керүе тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федеациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бинага һәм бүлмәләргә шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәмендә, биналар буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына, шул исәптән коляска-кресло ярдәмендә утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

4) күрү һәм үз-үзен йөртү функциясе нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәтләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне аларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып тиешле урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматларын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән ясалган билгеләр белән дубляжлау;

7) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт бирү;

8) махсус укытуны раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июненнән «Озатып йөри торган этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документы булганда, озатып йөрүче этне кертү мөмкинлеге.

9) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуга комачаулаучы башка киртәләрне җиңәргә ярдәм итүләре.

9) оказание работниками Министерства, предоставляющими государственную услугу, помощи инвалидам в преодолении иных барьеров, мешающих получению ими услуг наравне с другими лицами.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлар һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә файдаланыла торган чараларга инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки капиталь ремонт, реконструкцияләү, модернизацияләү үткән объектлар һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документлар кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3) Министрлык яки КФҮ хезмәткәрләренең Регламентны бозуларына нигезләнгән шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүче һәм вазыйфаи затларның үзара тәэсир итешүе саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Министрлык яки КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

Министрлык яки КФҮ тә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән бер үзара хезмәттәшлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, ДХБП, Республика порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү, бирү алып барыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;

2) белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмати стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында тулы мәгълүмат булуы;

4) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидлар өчен башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган биналарның һәркем өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү белән бәйле булмаган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтүе.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче ДХБП да, Республика порталында шәхси кабинетында, Министрлыкта, КФҮ тә алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматларга, хезмәт күрсәтү тәртибенә һәм башка документларга керү мөрәҗәгать итүченең ДХБП, Республика порталындагы шәхси кабинетында алдан авторизацияләнмичә башкарыла.

ДХБПда, Республика порталында шәхси кабинетта авторизацияләнгәннән соң, гариза бирүченең түбәндәге мөмкинлекләре бар:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза бирү;

2) кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон образларын (график файлларны) беркетү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада тапшыру мөмкинлеген тәэмин итү өчен, гариза бирүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын алу өчен (алга таба – гади электрон имза) гариза бирүчегә ИАБС да теркәлү процедурасын үтәргә кирәк. ИАБСда алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге сайтта («Интернет» челтәрендә сайтның домен исеме– esia.gosuslugi.ru/) урнаштырылган.

ИАБСда (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң, гариза бирүче–физик зат, гади электрон имза кулланып, ДХБП, Республика порталында авторизацияләнергә тиеш. ДХБП, Республика порталында шәхси кабинетта

авторизацияләнгәннән соң, гариза бирүче элек бирелгән гаризаларына һәм электрон рәвештә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә керә ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре исәпкә ала торган;

дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәткәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

- ДХБП да һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат алырга;

- электрон документ рәвешендә ДХБП, Республика порталындагы шәхси кабинеттан файдаланып, гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

- электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

- ДХБП, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

- хәбәрнамә формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

- ДХБП, Республика порталы, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәлсезлеккә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә карарларына һәм башкарылган гамәлләренә (гамьсезлеккә) шикаять бирү.

2.14.2. Гаризаны формалаштыру, башка нинди дә булса формада гаризаны өстәмә бирү зарурлыгыннан тыш, ДХБП да, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү (гариза кабул итү һәм консультация бирүдән тыш) КФҮ тә гамәлгә ашырылмый.

Гариза бирүчеләрне КФҮ тә кабул итү өчен язылу (алга таба – язылу) ДХБП, Республика порталы, КФҮ нең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә кабул итү өчен КФҮ тә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге дата башланганчы бер тәүлек алдан тәмамлана.

ДХБП, Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүчегә система сорый торган мәгълүматны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) телефон номеры;

3) электрон почта адресы (теләк буенча);

4) кабул итү датасы һәм вакыты.

Әгәр дә гариза бирүче алдан язылганда биргән мәгълүматлар гариза бирүче

шәхси кабул итү вакытында биргән документларга туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, гариза бирүчегә талон-раслауны бастыру мөмкинлеге тәэмин ителә. Әгәр дә мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда, гариза бирүчегә алдан язылуның билгеләнгән вакыттан унбиш минут узгач, ул килмәгән очракта гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә мәгълүмат бирелә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтү, шулай ук кабул итү өчен броньланырга тиешле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүмат бирүдән тыш, башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау чират тәртибендә мөрәҗәгать итүгә комачаулык итми.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Министрлык биналарындагы гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмати стендларда урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында мәгълүмат, Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннар, эш вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигын ала.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге мәгълүмат системалары кулланыла: ДХБП, Республика порталы, «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү.
3.1.1. . Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән гариза һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара сораулар (запрослар) формалаштыру һәм юллау;

4) Министрлыкның документлар комплектын каравы;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре) әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (юллау);

7) техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм итү (алга таба – мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү).

3.2. Консультирование заявителя, оказание помощи заявителю, в том числе в части оформления заявления, необходимого для предоставления государственной услуги (далее – консультирование заявителя).

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып:

- мөрәҗәгать итүче КФҮ кә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

- мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тора.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе һәм вакытлары турында консультация алу өчен КФҮкә шәхсән, телефон аша һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән тапшырыла торган документация составы һәм формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча да консультация үткәрә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ нең рәсми сайтында (http://mfc16.tatarstan.ru) алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнелә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе: булып тапшырыла торган документация составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәк булган башка мәсьәләләр буенча консультацияләр тора.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук ДХБП, Республика порталы, Министрлык сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып: тапшырыла торган документация составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр тора.

3.3. Гариза бирүче тапшырган гариза һәм документлар комплектын кабул итү һәм теркәү.

3.3.1.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, ДХБП, Республика порталы, КФҮ аша гариза бирә ала.

3.3.1.2. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итү.

Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.6.1 пунктына ярашлы рәвештә документлар тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итүне алып баручы КФҮ белгече КФҮ регламентларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән срокларда башкарыла.

Процедура үтәлешенең нәтиҗәсе булып электрон хезмәттәшлек системасы аша Министрлыкка юлланган гариза һәм документлар пакеты тора.

3.3.1.3 Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ДХБП, Республика порталы аша документларны электрон формада кабул итү.

Гариза бирүче электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) авторизацияләү үтә;

2) электрон гариза формасын ача;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

4) электрон гариза формасына документларны электрон формада яки электрон документлар үрнәкләрендә беркетә (кирәк булганда);

5) электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

6) хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

7) тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

8) электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне оештыру турында» 210-ФЗ законы (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә имзалана;

- электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Запросны формат-логик тикшерү ДХБП тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан запросның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында гамәлгә ашырыла. ДХБП электрон сорау формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.

Гариза язганда гариза бирүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасына элегрәк кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән керткәндә һәм яңадан кертү өчен кире кайтканда хаталар килеп чыкканда саклау;

4) ИАБС да урнаштырылган, ДХБП да басылган ИАБС да булмаган белешмәләргә кагыла торган өлештәге мәгълүматларны кулланып, гариза бирүче мәгълүмат кертә башлаганчы, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

5) электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этабына элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча кире кайту мөмкинлеге;

6) гариза бирүченең ДХБП да элек бирелгән гаризаларга бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга 3 айдан да ким булмаган вакыт эчендә керү мөмкинлеге.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәләре булып электрон хезмәттәшлек системасы аша Министрлыкка юлланган электрон эш тора.

3.3.1.4. Министрлыкның документлар комплектын кабул итүе.

Административ процедураны башкаруны башлап җибәрү өчен нигез булып гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар керү тора.

Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, мөрәҗәгать итүче гариза белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта:

1) мөрәҗәгать предметын билгели;

2) гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

3) документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерүне уздыра;

4) тапшырылган документларның Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда припискалар, сызылган сүзләр һәм башка әйтелмәгән төзәтүләр булмау) тикшерә;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

6) Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшырганда, тапшырылган документларны сканер аша үткәрә;

7) гаризаны бастыра;

8) тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә бирә;

9) кул куйганнан соң имзаланган гаризаны сканерлый;

10) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки сканерланган документларның электрон образларын йөкли, электрон эш формалаштыра;

11) гариза бирүчегә имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын кире кайтара;

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү өчен сәбәпләр булуы турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара. Гариза һәм документларны почта, КФҮ аша алганда, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәбен язмача аңлатып, гариза һәм документларны кире кайтара.

Документларны кире кайтарган очракта, гариза бирүче квалификация категориясен бирү өчен документларын алганнан соң 20 эш көне эчендә туры килмәүләрне бетерә һәм карау өчен аларны оешмага яңадан җибәрә.

Документлар электрон формада бирелгән очракта документлар кире кайтарылмый.

Гариза бирүче соравы буенча шәхсән мөрәҗәгать иткәндә документларны кабул итүдән язмача баш тарту бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

Әлеге пунктчада күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, автомат режимда дәүләт һәм муниципаль күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып башкарыла

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булмаганда, гариза теркәлә.

Әлеге пунктчада күрсәтелгән процедуралар карауга гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар үтәлеше нәтиҗәләре булып теркәлгән гариза яки документларны кабул итүдән баш тарту турында карар тора.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы запрос юллау өчен нигез булып тора.

3.4.2. Ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документ һәм белешмәләрне бирү турындагы запросларны әзерли һәм (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып) җибәрә.

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле сорала торган документлар исемлеге:

1) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы мәгълүмат. Запрос Федераль нотариаль палатага җибәрелә;

2) яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү хисабы турында мәгълүмат. Запрос Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

3) РФ гражданы паспортының гамәлдә булуы турында мәгълүмат. Запрос Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә.

Ведомствоара мәгълүмати запрос гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза һәм аңа теркәлеп бирелгән ддокументлар теркәлгән көнне башкарыла.

3.4.4. Ведомствоара запрослар буенча Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июненнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 963 номерлы карарына ярашлы рәвештә, әлеге документлар электрон формада булган органнар тарафыннан тиешле ведомствоара запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарыла ала:

1) соралган мәгълүматлар электрон формада булмау сәбәпле, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның оригиналын кәгазьдә тапшыру кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә башкарыла икән, Регламентның 2.6.3 пунктчасында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге документлар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ маддәсендәге 3 өлешенә ярашлы рәвештә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара запрос килгән көннән алып биш эш көненнән артмаска тиеш.

Процедура нәтиҗәсе булып соралган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган мәгълүматларны) алу яисә ведомствоара запрослар юллау өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган соралган мәгълүматларның булмавы турында хәбәрнамә.

Мәгълүматларны куллану максатлары булып гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм гариза бирүче хокукларын бозуны булдырмаучы карарлар кабул итү тора.

3.5. Министрлыкның документлар комплектын каравы.

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны карау өчен җаваплы вазыйфаи зат документларның формалаштырылган комплектын Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавына карый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ведомствоара запросларга җаваплар килгән көннән алып 11 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураны үтәү нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның каралган комплекты тора.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрне ачыклаганда, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында боерык белән рәсмиләштерелгән карар проекты әзерли;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат җитәкчесенә килештерү өчен әзерләнгән спорт хөкемдары квалификация категориясе бирү турында боерык проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү өчен документлар комплектын карау тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып килештерүгә юлланган спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында боерык проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты тора.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вәкаләтле вазыйфаи зат җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча әзерләнгән проектта искәрмәләр ачыкланса, ул проектны әзерләү өчен җаваплы кешегә кире кайтарыла. Искәрмәләрне юкка чыгарганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проекты кабат килештерүгә тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү өчен документлар комплектын карау тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураны үтәү нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерләү өчен җаваплы вәкаләтле вазыйфаи зат җитәкчесе тарафыннан килештерү яки проектны эшләп бетерү өчен дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтару тора

3.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең килештерелгән проекты дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы кеше тарафыннан имзалау өчен министрга (аның вазыйфаларын башкаручыга) җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү өчен документлар комплектын карау тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураны үтәү нәтиҗәсе булып министр (аның вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан имзаланган спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында боерык яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар тора.

3.6.4. Регламентның 3.6.1 – 3.6.3 пунктчаларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү (бирү).

3.7.1. Гариза бирүче шәхсән яки почта элемтәсе аша мөрәҗәгать иткәндә документлар җибәрү (бирү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документациясе алып бару подсистемасына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматларны теркәү һәм кертүне тәэмин итә;

2) гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Регламентның 2.3.6 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсен җибәрә (бирә);

3) Министрлыкның рәсми сайтында спорт хөкемдары квалификация категориясе (хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләреннән тыш) бирү турында боерык урнаштыра.

Техник мөмкинлек булганда, процедуралар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны министр (аның вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан имзалау көнендә башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре: Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен урнаштыру, гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

Квалификация категориясе биргәндә, Министрлык тарафыннан тиешле күкрәк билгесе һәм спорт хөкемдары китапчыгы бирелә.

3.7.2. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә электрон документ нөсхәсе формасында кәгазьдә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә.

Гариза бирүче таләбе буенча, кәгазьдә электрон документ нөсхәсе белән бергә, аңа күчереп йөртелә торган мәгълүмат йөртүчегә язып, яки электрон почта аша гариза бирүче адресына юллау ысулы белән электрон документ экземплярын бирә. Электрон документ экземплярын күчереп алына торган мәгълүмат йөртүчегә язганда яисә аның нигезендә кәгазьдә электрон документ экземпляры төзелгән электрон документ экземплярын электрон почта аша җибәргәндә,

электрон документ экземплярының кәгазьдәге электрон документ экземплярына тәңгәллеге вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып раслана.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе КФҮ эш Регламентында билгеләнгән срокларда, әмма Министрлыктан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүче КФҮ эш Регламентында билгеләнгән срокларда килгән көнне чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып Татарстан Республикасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (юллау) фактын теркәү, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

3.7.3. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен ДХБП, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең шәхси кабинетына министрның (аның вазыйфаларын башкаручы затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документның электрон үрнәге автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаучы документка кул куелган көнне башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып ДХБП, Республика порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ җибәрү (бирү). тора

3.7.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә (җибәрә). Гариза бирүче таләбе буенча электрон документ экземпляры белән бергә кәгазьдә аңа электрон документ экземпляры бирелә, аны күчереп йөртә торган мәгълүмат йөртүчегә язып яки электрон документ экземплярын электрон почта аша гариза бирүче адресына җибәрәләр.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә гариза бирүче килгән көнне тапшырыла.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) нәтиҗәсе булган документны министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзалау көнендә башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) нәтиҗәсен бирү тора.

3.7.5. Хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләренә карата кабул ителгән карар турындагы документның күчермәсе Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылмый, һәм ул имзаланганнан соң биш эш көне эчендә федераль орган бүлекчәсенә җибәрелә яки вазыйфаи затка тапшырыла.

3.7.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат аларны гариза

бирүчегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә кире кайтара.

Спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү өчен документлар электрон формада бирелгән очракта документлар кире кайтарылмый.

3.8. Техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хатаны) (алга таба – техник хата) төзәтү

3.8.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне җибәрә:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;

3) юридик көчкә ия, техник хата булуын раслаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан түбәндәге ысуллар белән: Министрлыкка шәхсән, почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә ДХБП, Республика порталы, КФҮ аша бирелә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү датасыннан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.2. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентта каралган процедураларны гамәлгә ашыра, техник хата булган документ оригиналын алу белән, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны бирә яисә мөрәҗәгать итүчегә почта аша (электрон почта аша), Министрлыкка техник хаталы документ оригиналын тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ тора.

## 4.Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү формалары

4.1. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы җаваплы вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Регламент нигезләмәләренең һәм башка норматив хокукый актларның сакланышын һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне

агымдагы тикшерү министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан Регламент нигезләмәләренең үтәлешен һәм үтәлешен тикшерү юлы белән башкарыла.

Агымдагы тикшерү даими нигездә башкарыла.

4.2. Административ процедураларның үтәлешен саклауны тикшерү формалары булып:

-1) эш алып бару;

2) документларны карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (Регламентка) туры килүе;

3) документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен үтәү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү вакытларын һәм тәртибен үтәү.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элегрәк ачыкланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Регламент таләпләрен һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны юкка чыгаруны тикшерү белән бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга китергән Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять белән мөрәҗәгатьләре.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре ачыкланган кимчелекләрне һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәрне билгеләүче акт белән рәсмиләштерелә.

4.6. Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта гаепле дип табылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр һәм шикаятьләрне судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләренең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең

гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирергә хокуклы.

Министр кабул иткән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга, гамәлләргә (гамьсезлегенә) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

КФҮ хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә, КФҮ карарларына, гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаятьләр КФҮ оештыручысына бирелә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында бирү яки гамәлгә ашырылу каралмаган документлар яисә мәгълүматлар бирүне яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле рәвештә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) шикаять ителә торган КФҮ га 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтен тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, гариза бирүче тарафыннан КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) буенча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда дәүләт хезмәтен күрсәтү

өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгәндә яисә 210-ФЗ федераль законының 7 маддәсе 1 өлеше 4 пункты белән каралган очраклардан тыш дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда аларны таләп итү. Күрсәтелгән очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) шикаять ителә торган КФҮ га 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 маддәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтен тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, гариза бирүче тарафыннан КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) буенча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин.

5.3. Шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Министрлык, Министрлык хезмәткәре карарлары һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан файдаланып, ДХБП, Республика порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхсән кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарлары һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) шикаять почта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, КФҮ рәсми сайтыннан файдаланып, ДХБП, Республика порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхсән кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять кергән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән унбиш эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына дәгъва белдерелгән очракта яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесе яки хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), тору урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләре.

5.6. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчерелмәләре тәкъдим итәлергә мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип тапкан очракта, гариза бирүчегә әзерләнгән җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык, КФҮ тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук җибәрелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә алга таба дәүләт хезмәтен алу максатларында кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта әлеге кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карар буенча шикаять язу тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләр карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

5.9. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Спорт хөкемдарлары
квалификация категорияләрен
бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең
Административ регламентына
1 нче кушымта

*(Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган бланкы)*

**Спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында**

Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәне үтәү нигезендә

б о е р а м:

Ф.И.Аи. (Аи – булганда) Спорт төре

«Беренче категория спорт хөкемдары» спорт хөкемдары квалификация категориясен бирергә.

Министр
(аның вазыйфаларын башкаручы зат) Мөһер урыны Ф.И.Аи. (Аи. – булганда)

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

## Спорт хөкемдары квалификация категориясен бирүгә тәкъдим

______________________________________________________________

(спорт хөкемдарының квалификация категориясе күрсәтелә)

0

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тәкъдим һәм документларның керү датасы (число, ай, ел) | | | | фото | Спорт хөкемдарының гамәлдәге квалификация категориясе атамасы | | | | Рәсми спорт ярышы уздыру вакытлары ( кк/аа/ее – кк/аа/ее) | Рәсми спорт ярышының атамасы һәм статусы | Спорт хөкемдарының вазыйфасы атамасы һәм хөкемдарлык өчен бәя |
| Фамилия | | | | 3х4 см | Спорт хөкемдарының гамәлдәге квалификация категориясен бирү датасы (число, ай, ел) | | | | | | |
| Исеме | | | | | | | | | | | |
| Атасының исеме (булганда) | | | | | | | | | | | |
| Туу датасы (число, ай,ел) | | | | Спорт төре атамасы | | | | | | | |
| Россия Федерациясе субъекты | | | | Спорт төренең номер-коды | | | | | | | |
| Эш (уку) урыны, вазыйфасы | | | | Спорт хөкемдарының хөкемдарлык эшчәнлеген исәпкә алуны гамәлгә ашыручы оешманың атамасы һәм адресы (урнашкан урыны) | | | | | | | |
| Белеме | | | | Спорт исеме (булганда) | | | | | | | |
| Теоретик дәресләрдә катнашу, физик әзерлек буенча тестлар үтәү (мондый тестлар спорт төре кагыйдәләрендә каралган спорт төрләре өчен), квалификация зачетын тапшыру (имтихан) | | | | | Дата (число, ай, ел) | | | Бәя | | | |
| 1 | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | |
| ____________________________________________ Региональ спорт федерациясе, физкультура-спорт оешмасы яки хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләрен үстерүгә җитәкчелек итүче федераль башкарма хакимият органы бүлекчәсе атамасы | | | | | | | | | | | |

| | |
|---|---|
| Вазыйфа (Фамилия, инициаллар)<br>____________________ ____________________________<br><br>____________________ ________________________<br>Дата (число, ай, ел) Имза<br><br>Мөһер урыны (булганда) | |

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына
3 нче кушымта

Форма

## Спорт хөкемдарының хөкемдарлык эшчәнлеген исәпкә алу карточкасы

| | | |
|---|---|---|
| **СПОРТ ХӨКЕМДАРЫНЫҢ ХӨКЕМДАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕН ИСӘПКӘ АЛУ КАРТОЧКАСЫ** | **Спорт төре атамасы** | |
| | **Спорт төре номер-коды** | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Фамилия** | | **Исеме** | | **Атасының исеме** (булганда) | | **Туу датасы** | | | **Фото 3x4 см** |
| | | | | | | **көн** | **ай** | **ел** | |
| **Россия Федерация-се субъекты** | | **Муниципаль берәмлек** | | **Әлеге спорт төрендә спорт званиесе** (булган очракта) | | | | | |
| | | | | | | **Спорт хөкемдарының хөкемдарлык эшчәнлегенең башлану датасы** | | | |
| | | | | | | **көн** | **ай** | **ел** | |
| **Белеме** | | | | | | | | | |

| | |
|---|---|
| **Эш (уку) урыны), вазыйфасы** | |
| **Элемтә өчен телефоннары, электрон почта адресы** | |

**Спорт хөкемдарының хөкемдарлык эшчәнлеген исәпкә алуны гамәлгә ашыручы оешма**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Атамасыы** | | **Адрес** (урнашкан урыны) | | **Телефон, электрон почта адресы** | |

| **Спорт хөкемдарының квалификация категориясе** | **Бирелгән/ расланган/ мәхрүм ителгән/** | **Бирелү/ раслану/ мәхрүм ителү/ яңадан торгызылу турында** | **Спорт хөкемдары квалификация категориясе бирелү/раслану/ мәхрүм ителү/ яңадан торгызылу турында карар** | **Документны имзалаган вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары** | **Оешманың мөһере, исәп карточкасын рәсмиләштерү өчен җаваплы кешенең** |
|---|---|---|---|---|---|

| атамасы | яңадан торгызылган | документ реквизитлары | | кабул иткән оешма атамасы | | имзасы, фамилиясе һәм инициаллары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **Дата** (көн, ай, ел) | **Номер** | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

## ТЕОРЕТИК ӘЗЕРЛЕК, ФИЗИК ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ТЕСТЛАРНЫ ҮТӘҮ, КВАЛИФИКАЦИЯ ЗАЧЕТЫН (ИМТИХАНЫН) БИРҮ

| **Теоретик әзерлектә катнашу** | | | | | **Квалификацион зачетны (имтиханны) тапшыру** | | | **Физик әзерлек буенча тестларны башкару** | | | | **Үткәрүче оешма, язманы кертү датасы, исәп карточкасын рәсмиләштерү өчен җаваплы затның имзасы, фамилиясе һәм инициаллары** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Лектор буларак** | | | **Катнашучы буларак** | | | | | | | | | |
| **Дата** (көн, ай, ел) | **Уздыру урыны** (адресы) | **Бәя** | **Дата** (көн, ай, ел) | **Уздыру урыны (адресы)**) | **Дата** (көн, ай, ел) | **Беркетмә № ы** | **Бәя** | **Дата** (көн, ай, ел) | **Уздыру урыны (адресы)**) | **Спорт хөкемдарының вазыйфасы, тестның атамасы, нәтиҗәсе** | **Билге** | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

## РӘСМИ СПОРТ ЯРЫШЛАРЫНДА ХӨКЕМДАРЛЫК ПРАКТИКАСЫ

| **Уздыру датасы** | **Уздыру урыны** (адресы) | **Спорт хөкемдары вазыйфасының атамасы** | **Рәсми спорт ярышларының атамасы һәм статусы, программа төре** | **Билге** | **Язманы кертү датасы, исәп карточкасын рәсмиләштерү өчен җаваплы затның имзасы, фамилия һәм инициаллары** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

*(Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бланкы)*

Кемгә: ___________________________

______________дән №лы________________

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

КАРАР

Сезнең ________________нән ________ номерлы гаризагызны һәм аңа теркәп бирелгән документларны карагач, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча спорт хөкемдарының квалификация категориясенә ия булу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. ________________________________________________________________;
2. ________________________________________________________________.

Баш тарту өчен сәбәпләрне аңлату: ________________________________________

Өстәмә мәгълүмат: _______________________________________.

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне юкка чыгарганнан соң, хезмәт күрсәтү турында гариза белән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына судка кадәр шикаять бирү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
| --- |

Вазыйфаи зат Ф.И.Аи. (Аи. – булганда)

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

*(Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бланкы)*

*Кемгә:* ________________________

_____________ нән № _____________лы

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

Сезнең ________________нән _________ номерлы гаризагызны һәм аңа теркәп бирелгән документларны карагач, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча

1.____________________________________________________________________;

2.____________________________________________________________________

кандидат

________________________________, туу датасы: ____________________, спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Өстәмә мәгълүмат: _________________________________________.

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне юкка чыгарганнан соң, хезмәт күрсәтү турында гариза белән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына судка кадәр шикаять бирү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Вазыйфаи зат Ф.И.Аи. (атасының исеме – булганда)

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына

(оешма атамасы, оешма җитәкчесе яки оешма вәкиленең Ф.И.Аи. (атасының исеме – булганда)

________________________________________

_____________________________________дан

техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Дәүләт хезмәте күрсәткән чакта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм:

__________________________________________________________________________
(хезмәт атамасы)

Язылган:____________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:__________________________________________________

__________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.______________________________________________________________;

2.______________________________________________________________;

3.______________________________________________________________;

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул иткән очракта әлеге карарны түбәндәге ысул белән юллавыгызны сорыйм:

__________________________ e-mail адресына электрон документ юллап;

карарның кәгазьдә расланган нөсхәсен түбәндәге адрес буенча почта аша юллап:_____________________________________________________________.

Әлеге имзам белән гаризага кертелгән һәм минем шәхескә һәм мин вәкиле булган затка карый торган мәгълүмат, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматның хаклыгын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматка ия.

________________                    ________________ ( ______________________)

(дата)                          (имза)        (Ф.И.Аи. (атасының исеме – булганда)

Спорт хөкемдарлары
квалификация категорияләрен
бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең
Административ регламентына
кушымта (белешмә)

Спорт хөкемдарлары квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен тикшереп тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 222-81-02 | minsport@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 222-81-09 | minsport@tatar.ru |
| Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы | 222-81-44 | minsport@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләре буенча идарә башлыгы | 264-77-84 | prav@tatar.ru |